Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№11 (104)

10 апрель 2014 ел



# «Шпагатка утырырга гына өйрәнәсе калды!»

Эш кешесе булдырдым дип сөенә, күңеле күтәрелә. Шушы тойгы кабатлана торгач, аны киң күңелле итә – эше җайлы кеше юмарт, ярдәмчел була. Ә кызыксыз эшләр юк. Илһамланып, яратып тырышкан кешенең эше бүтәннәргә дә кызыклы була! *Ш.Галиев*

## • Вакыйгалар эзеннән

Шушы көннәрдә Н.И.Лобачевский ис. лицейның 11 А сыйныфында белем алучы **ДЕНИС ГАЛИӘКБӘРОВ** Смоленскида уздырылган тарих буенча Бөтенроссия олимпиадасының призерлары рәтенә керде. Денисны бу уңышы белән котлыйбыз!

• • • •

**6 АПРЕЛЬ** көнне КФУның ИТИС Югары мәктәбендә үзенчәлекле **АЧЫК ИШЕКЛӘР КӨНЕ** булды. Югары уку йортына керү кагыйдәләре белән таныштыра торган гадәти лекциядән тыш, булачак студентларга компьютер уеннарын уйлап чыгару буенча мастер-класс күрсәтелде. Шулай ук абитуриентлар арасында Counter Strike уены буенча Чемпионат та уздырылды. Институт белән якыннанрак танышу өчен, Казанга Россиянең төрле төбәкләреннән килгән укучылар берничә командага бүленде. Аяусыз көрәштә IT-лицей укучылары җиңеп чыкты. Барлык финалистларга бүләкләр һәм дипломнар тапшырылды.

• • • •

**7 АПРЕЛЬ** көнне КФУда ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ** чираттагы **УТЫРЫШЫ** булды. Гадәттәгечә, контроль йөкләмәләрнең үтәлеше белән Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** таныштырды. Алга таба Россия һәм БДБ MathWorks Департаменты җитәкчесе Н.Богославский MATLAB программасын тәкъдир итте. Ул ректорат вәкилләрен фирманың эшкәртмәләре белән таныштырды. Оешма компьютер модельләштерүе һәм хисаплау өлкәсендәге программалы тәэмин ителеш ясау белән шөгыльләнә. И.Гафуров структур бүлекләр җитәкчеләренә оешма продукциясе белән танышырга һәм үз фикерләрен әйтергә тәкъдим итте. Аннан соң «КФУда электрон укыту системасы» турында Белем бирү ресурсларын үстерү департаменты директоры **Г.ИВШИНА** сөйләде. Аның әйтүенчә, департамент уку елы ахырына дистанцион уку өчен 312 электрон белем бирү программасы булдырырга ниятли. Мәгълүматлаштыру һәм элемтә департаменты директоры **Д.БУРМИСТРОВ** КФУның спорт объектларында ір-камералар урнаштыру турында мәгълүмат җиткерде. КФУның төбәкара фән олимпиадалары һәм Н.И.Лобачевский ис. лицей укучыларының XV Идел буе конференциясенең нәтиҗәләре белән Вузга кадәрле, гомуми һәм педагогик белем бирү департаменты директоры **Л.НОГМАНОВА** таныштырды. Аның сүзләре буенча, быел олимпиадада 2104 укучы катнашкан. Конференциягә исә барысы 546 эш кабул ителгән.

• • • •

Татарстанның Тормыш иминлеге нигезләре укытучылары арасында уздырылган конкурста Физик тәрбия, спорт һәм тернәкләндерү медицинасы институты читтән торып уку бүлегенең 6 курс студенты **РАЗИХ КАМАЛОВ БЕРЕНЧЕ** урынга лаек булды.

• • • •

**7 АПРЕЛЬДӘ** КФУның Алабуга институтында **ПСИХОЛОГИЯ АТНАЛЫГЫ** башланып китте. Атна буе бу уңайдан төрле тренинглар, мастер-класслар һәм психология буенча факультетара олимпиада үткәреләчәк. Бу юлы атналык психология кафедрасының 25 еллык юбилеена багышлана.

• • • •

**7 АПРЕЛЬ** көнне КФУда ел саен үткәрелә торган **«СӘЛАМӘТЛЕК КӨНЕ» АКЦИЯСЕ** узды. Аның кысаларында студентлар өчен сәламәтләндерү практикалары һәм техникалары буенча мастер-класларда катнашу, дәвалау-педагогик скрининг процедурасын үтү, төрле тип бәйлелек мәсьәләләре буенча белгеч һәм психологка мөрәҗәгать итү мөмкинлекләре тудырылды. Әлеге чара Казан универстетында инде дүртенче тапкыр үткәрелә.

• • • •

Шул ук көнне Сәламәтлек көне кысаларында **МИНИ-ФУТБОЛ ЯРЫШЫ** узды. Алдагы уеннар нәтиҗәсендә, ярымфиналга Экология һәм география, Геология һәм кара алтын-газ технологияләре, Физика институты һәм Яр Чаллы институты командалары чыкты. Финал өлешендә физиклар һәм Яр Чаллылар көч сынашты. Анда 2:1 исәбе белән **ФИЗИКА ИНСТИТУТЫ ҖИҢҮ ЯУЛАДЫ**. Аларны әлеге уңышлары белән тәбрик итәбез!

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Хезмәттәшлек



# Чит илләргә юл

Дания ФАТЫЙХОВА

8 апрель көнне КФУ һәм Росхезмәттәшлек арасында хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә кул куелды. Чарада КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм агентлык җитәкчесе Константин Косачев катнашты.

Росхезмәттәшлек – чит илләрдә яшәүче ватандашларыбызның БДБ эшләре һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек буенча федераль агентлыгы. 2008 елда барлыкка килгән бу оешма 77 илне үз эченә ала, шуларның 59ында Россиянең фән һәм мәдәният үзәкләре булдырылган. География буенча карасак, оешма АКШтан Япониягә, Финляндиядән Аргентинага кадәр территорияне биләп тора.

Әлеге килешү мәгариф, фән, мәдәният өлкәләрендә халыкара хезмәттәшлеккә, чит ил гражданнарын Россиягә, аның теленә, мәдәниятенә, тарихына, белем бирү системасына һәм Россиядә белем алуга җәлеп итүгә юнәлдерүне максат итеп куя.

Очрашу кысаларында ике як та уку йортларының эшчәнлекләре турында сөйләде. Аларда студентлар өчен тудырылган мөмкинлекләр, фәнни-мәгариф потенциаллар турында мәгълүмат җиткерелде. К.Косачев агентлыкның Россия мәгарифен чит илдә таныту, чит ил студентларын безнең илгә җәлеп итү буенча эшчәнлеге белән таныштырды. Җитәкче югары уку йортлары белән хезмәттәшлек итү агентлыкның приоритетлы юнәлеше булуын әйтте.

*Мәгълүмат КФУның Матбугат үзәгеннән алынды*

• Белем баскычлары

# Agilent Technologies белгечләреннән – семинар

Дания ФАТЫЙХОВА

8 апрель көнне Физика институтында Agilent Technologies оешмасы вәкилләре семинар уздырды. Ул югары һәм бик югары ешлыклы чыбырлар, модульләр һәм тоеннәрне Agilent автоматлаштырылган проектлаштыру системасы ярдәмендә модельләштерү мәсьәләсенә багышланган иде.



Влад Михневский фотолары




Agilent Technologies контроль-үлчәү җиһазлары җитештерү буенча лидерлар рәтендә санала. Оешма электрон үлчәү, химия анализы, биотехнологияләр һәм геном диагностикасы юнәлешләрендә эшчәнлек алып бара. Компаниянең университетлар өчен әзер белем бирү курслары һәм материаллары да бар. Agilent Technologies КФУ белән беренче ел гына хезмәттәшлек итми.

Семинарда студентлар да, укытучылар да, төрле оешма вәкилләре дә катнашты. Очрашуда компания вәкилләре ADS программасының яңа версиясе һәм Electromagnetic Professional автоматлаштырылган проектлаштыру системасы турында тәфсилләбрәк сөйләделәр. ADS 2014 системасына MMIC модульләре һәм югары ешлыклы платаларны модельләштерүне җиңеләйтергә ярдәм итә торган яңа мөмкинлекләр өстәлгән. Төгәлрәге, яңа версиядә электротермаль анализ өчен җавап бирә торган элемент барлыкка килгән.

Electromagnetic Professional (EMPro) системасын Agilent Technologies компаниясенең 3D ЭМ модельләштерү өлкәсендә техник белгеч вазифасын башкарган ХиСу Ли тәкъдир итте. ХиСу Ли радиоэлектрон җайланмалар проектлаштыру өлкәсендә 25 еллык хезмәт стажына ия.

Electromagnetic Professional система 3D объектлар барлыкка килү өчен тирәлек тудыра. EMPro ADS белән уңайлы интеграцияне дә тәэмин итә.

Семинарда катнашучыларга оешма тормышындагы истәлекле яңалык хакында да сөйләделәр. Билгеле булганча, Agilent Technologiesның төп ике юнәлеше бар: үлчәү һәм химия анализы өчен җиһазлар ясау. Узган ел ахырында компания җитәкчелеге оешманы бүләргә карар кыла: 2014 елның ноябрендә контроль-үлчәү продуктлары яңа «Keysight Technologies» бренды белән чыга башлаячак. Шул рәвешле һәр компания күбрәк игътибарны үз юнәлешенә җәлеп итү өчен тырышачак.

• Чара

Шушы көннәрдә Каюм Насыйри ис. XII Халыкара яшүсмерләр фәнни-тикшеренү укулары узды. Ул Казанның Киров районында урнашкан 81нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбендә оештырылган иде. Мондый төр чаралар ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәме белән уткәрелә.

# Каюм Насыйри җыены

Рөстәм ФӘРХУЛЛИН,
Экология һәм география институты ассистенты



Балалар әлеге чарада бик актив катнашты. Барлыгы 375 эш тәкъдим ителгән иде. Укулар 14 секциягә бүленеп алып барылды. Аларны КФУның Экология һәм география институты географик һәм экологик белем бирү бүлеге, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани ис. тарих институты укытучылары җитәкләде.

Башка еллардан аермалы буларак, быел беренче тапкыр «Кеше сәламәтлеге» секциясе эшләде. Катнашучыларның географиясе дә шактый киң иде: ТРның күпчелек районнары, Казан, Яр Чаллы шәһәре, Оренбург һәм Ульян өлкәләре, Башкортстан һәм Чуваш республикалары. Чарада катнашучылар өчен матур концерт та оештырылган иде.



• Туган тел сагында

# Тел үсеше – көнүзәк мәсьәлә

Галия СӘЛИМОВА

Хәзерге көндә туган телләрне саклау һәм үстерү иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. 4 апрельдә КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында узган «Гомумроссия гражданлык тәңгәллеге чыганагы буларак Россия Федерациясе субъектларында туган тел һәм дәүләт телләрен үстерү» дип аталган фәнни-гамәли конференциядә дә нәкъ менә шул мәсьәлә буенча фикер алыштылар.





Көн дәвамында ФһМБИ һәм Ш.Мәрҗани ис. 2 гимназия базасында телләрне үстерү темасына багышланган 8 секция эшләде. Чарада Татарстаннан гына түгел, Башкортстан, Чувашстан, Марий Эл, Удмуртия, Хакасия республикаларыннан килгән катнашучылар һәм кунаклар да бар иде.

Конференция пленар утырыш белән тәмамланды. Телне саклау, үстерү турыдан-туры филологлар, тел галимнәре эшчәнлеге белән бәйле. Утырышта ФһМБИ директоры, профессор Рәдиф Җамалетдинов та моның шулай икәнлеген ассызыклады. КФУда югары филологик белем бирү мәсьәләсен күтәреп, ул институтның бу юнәлештә белгечләр әзерли торган төп өч бүлеге турында тәфсилләбрәк сөйләде. Бу очракта сүз Л.Толстой исемендәге рус һәм чит телләр филологиясе, Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлекләре, С.Сәйдәшев исемендәге Югары сәнгать мәктәбе хакында барды.

Катнашучыларга ФһМБИның татар теленә өйрәтә торган «Ана теле» проекты белән танышу мөмкинлеге дә бирелде. Бу онлайн-мәктәп ярдәмендә Россиядә яшәүчеләр генә түгел, чит ил кешеләре дә татар телен өйрәнә.

Казанның Мәгариф Идарәсе башкарма комитеты башлыгы Илсур Һадиуллин үз чыгышында телләр өйрәнүнең норматив-хокукый базасы мәсьәләсен күтәрде. Нигездә, ул «Татарстанда рус теле» республика программасы һәм «Татар халкының милли тәңгәллеген саклау» дәүләт программасы хакында сөйләде. И.Һадиуллин 1 марттан кертелгән яңалыкларга тукталып, катнашучыларга шәһәрнең барлык мәктәпләрендә дә ана телен өйрәнүгә өстәмә сәгать бирелүе хакында мәгълүмат җиткерде.

*Влад Михневский фотолары*

• Мөнбәр




■Сулдан уңга: М.Волкова, Л.Фәйзуллина, И.Тришин, А.Пую.

# Уеннан уймак

Ләйсән ФӘЙЗУЛЛИНА,
Казан шәһәре

Яратып башкарган эшеңнең нәтиҗәле булуы һәрберебездә дә канәгатьләнү хисе уята, әлбәттә. Бигрәк тә ниндидер уңышларга ирешү – үзе бер бәйрәмгә әверелә, алга таба да тырышырга, эшләргә, эзләнергә этәргеч булып тора. Минем тормышымда да күптән түгел шундый вакыйга булды. Үзе бик гади генә башланып киткән иде, югыйсә.

### Эшнең төше

Менә инде дүрт елга якын мин мәктәптә «Яшь журналистлар» түгәрәген җитәклим. «Школа радости» дип исемләнгән газета чыгарабыз. 2013 елның ноябрь аенда газетаны Санкт-Петербургның дәүләт университетына юлладым. Монда менә инде 4 ел «Журналистиканың югары мәктәбе» базасында мәктәп балалары өчен үткәрелә торган «Проба пера» дип исемләнгән журналистика, реклама һәм PR буенча Бөтенроссия конкурсы үткәрелә. Бу конкурста яшь журналистлар язу осталыгында көч сынаша, реклама һәм PR проектлар эшли, газеталар чыгара, телерепортажлар әзерли.

Конкурста барлыгы 48 газета редакциясе катнашып, шуларның 18е генә финалга чыкты. Нәтиҗәләр буенча безнең газета 8нче урында иде. Алга таба ярышу өчен Санкт-Петербургка чакыру алгач, мин бераз югалып калдым. Яшәү урыны эзләү, билетлар алу кебек мәшәкатьләр килеп басты. Тормыш иптәшем, хезмәттәшләрем, дусларымның ярдәме белән тора-бара барлык проблемалар хәл ителде. Конкурс таләпләре буенча, һәр газета редакциясеннән бер җитәкче һәм ике хәбәрче булырга тиеш иде. Минем түгәрәктә күбрәк 5-7нче сыйныф укучылары булганга күрә, иң актив ике баланы сайлап алдым: Маргарита Волкова (5нче сыйныф) һәм Иван Тришин (6нчы сыйныф).

...Бер тәүлектән, без Санкт-Петербургта идек. Эрмитаж, Исаакий соборы, Сарай мәйданында булдык. Шәһәрнең мәгърур биналарын карап, сокланып йөрдек.

### Без «ат карауччылар» булдык

Конкурс бик җитди булып чыкты. Беренчедән, монда Россиянең төрле почмакларыннан 180нән артык талантлы яшь журналистлар җыелган иде. Икенчедән, өлкән сыйныф укучылары өчен биремнәр олимпиада формасында әзерләнгән. Бу аларга әлеге уку йортына укырга кергәндә өстенлек бирә икән. Өченчедән, конкурс программасы бик бай эчтәлекле итеп төзелгән иде.

Беренче көнне ачылу тантанасында катнашучыларны институт директоры Анатолий Степанович Пую, конкурсны оештыручылар һәм спонсорлар сәламләде. «Ничек кенә авыр булмасын, сездә бу конкурс турында бары тик яхшы хатирәләр генә саклачак», – дип, катнашучыларга уңышлар теләделәр.

Индивидуаль катнашучылар өчен рус теле һәм әдәбиятыннан тестлар һәм «Антон тут рядом» (10-11 сыйныфлар өчен), «Сочи накануне» (8-9 сыйныфлар өчен) фильмнарына рецензия яки эссе язарга тәкъдим ителде. «Реклама һәм PR-проектлар» номинациясендә катнашучылар өчен «Сөйләм экологиясе» темасына проектлар әзерләү вазифасы йөкләнде. Тележурналистлар әлеге конкурс турында фильм төшерергә тиеш иде. Газета редакцияләре исә төрле һөнәр ияләре өчен өр-яңа газеталар чыгару белән шөгыльләнде. Безгә, мәсәлән, җирәбә буенча, ат карауччылар һөнәре эләкте. Кемдер аяк киеме тегүчеләргә, кемдер урман карауччыларга, ә кемдер хәтта мунчада эшләүчеләргә багышлап газета чыгарырга тиеш иде. А3 форматында ике полосадан торган газета ярты көн эчендә әзер булырга тиеш. Газетада мөхәррир сүзе, сорау-җавап, интервью, хроника һәм проблемалы мәкалә булуы мөһим иде. Шулай ук газетаның концепциясе аерым эшләнергә тиеш. Күпмедер дәрәҗәдә Интернет-ресурслардан файдаланырга мөмкин: терминнар, мәкаль-әйтемнәр, фоторәсемнәр алырга. Ләкин аерым текстлар редколлегия әгъзаларыныкы булырга тиеш.

Биремне бик яхшы башкарып чыктык. Укучыларым, катнашучылар арасында иң кечкенәләре булуга карамастан, 8-11нче сыйныф укучылары белән беррәттән катнаштылар һәм сынатмадылар.

### Журналистлар белән журналистлар

Конкурс кысаларында Санкт-Петербургның массакүләм мәгълүмат чараларына экскурсияләр планлаштырылган иде. Төркемнәргә бүленеп, журналистлар «НТВ-Петербург» телеканалына, «РИА-Новости» медиаүзәгенә, «Эхо Москвы в Санкт-Петербурге» радиостанциясенә, «Радио России» телерадиокомпаниясенә һәм «ИТАР-ТАСС», «БалтИнфо» мәгълүмат агентлыкларына бардылар.

Без Россиядәге иң дәрәҗәле һәм өлкән булган «ИТАР-ТАСС» агентлыгына бару бәхетенә ирештек. Агентлыкның шеф-редакторы Оксана Чернышева безгә бина эчендә экскурсия үткәрде, журналистларның көн тәртибе һәм эш үзенчәлекләре белән таныштырды. Бу агентлыкта О.М.Сердобольский, М.М.Фролов кебек күренекле журналистлар белән беррәттән, яшь белгечләр дә күп эшли икән. «ИТАР-ТАСС» хәбәрләре һәрвакыт беренче, төгәл, объектив һәм, әлбәттә, актуаль булырга тиеш. Әлеге экскурсия балаларга һәм минем үземә дә бик кызыклы булды. Укучылар үзләрен кызыксындырган сорауларны да бирергә өлгерделәр.

Конкурсның икенче көне вакыйгаларга тагын да бай булып чыкты. Балет артисты А.Галичанин, «НТВ» телеканалы журналисты Р.Герасимов һәм кино актрисасы, депутат А.Мельниковалар белән очрашу булды. Без А.Мельникова пресс-конференциясендә катнаштык. Аның тормышы, кызыксынулары турында белдек. Журналистлар белән мөнәсәбәтләре яхшы булуын әйтеп үтте. Актриса бик кызыклы шәхес булып чыкты.

Шулай ук бу көнне профессиональ журналистлар һәм PR белгечләре белән мастер-класслар булып узды. Без «РИА-новости» медиаүзәге җитәкчесе К.Шолмов үткәргән мастер-класста катнаштык. Ул журналистика тарихы, Россиядәге журналистиканың үзенчәлекләренә тукталып китте. Яшь журналистларга көн саен язарга, каләм чарларга киңәш бирде.

### Җиңү тәме

Мастер-класстан соң, тантаналы рәвештә нәтиҗәләр игълан ителде, конкурста җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылды. Мин безнең команда җиңү яулар дип бер дә көтмәгән идем. Шулай да компетентлы жюри нәтиҗәләре буенча без «Иң яхшы газета» номинациясендә III урын яулап алдык. Шундый дәрәҗәле конкурста эшебезне югары бәяләүләре горурлык хисе уятты. Өстәвенә, бу конкурста катнашып, мәктәп һәм шәһәребез данын яклау зур җаваплылык өстәде.

Шулай итеп, барлык киңәшләрне мыекка чорнап, яңа белемнәр туплап, без Казанга юл тоттык. Мондый яхшы конкурс оештырулары өчен Санкт-Петербург университетының «Журналистика һәм массакүләм коммуникацияләрнең югары мәктәбе» институты җитәкчелегенә, укытучыларына һәм волонтер-студентларына рәхмәтебезне белдерәсем килә. «Проба пера» кебек конкурслар күбрәк булсын иде.

***P.S.*** *Үзебезнекеләрдән хат алу нинди бәхет икән?! Ләйсән Фәйзуллинаны күпләр Тукмачева дип белә. ТДГПУны тәмамлап, 33нче мәктәптә эшли. Ләйсәннең уңышлары турында ишетеп, бик сөендек. Алга таба да уңышлар телибез, хезмәтттәшебез!*

• Син+Мин=БЕЗ!

# Чынбарлыктан әкият иленә!

Динә МӨХТӘСИПОВА

Кабарып торган күлмәкле, матур фраклы, күз явын алырлык кызлар, һәм егетләр узган гасырларга кайтты. 5 апрель көнне «Корстон» күңел ачу комплексында уку йортыбызның «Язгы балы» узды.







Чара быел икенче тапкыр оештырылды. Аны Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты студентлары үткәрә. Беренче тапкыр чараны институтның 35 еллыгына багышлыйлар һәм ул зур популярлык ала, шуңа күрә аны кабаттан уздырырга уйлыйлар. Әйтергә кирәк, әлеге чара КФУның «Ел студенты» бәйгесендә «Ел проекты» номинациясендә җиңү яулый.

Катнашучыларны Fleur de la dance борынгы биюләрне өйрәтү студиясе әзерләгән. Чарада катнашуга барлыгы 150 пар теләк белдергән. Регистрация үткәч, алар бер ай дәвамында котильон, фигуралы вальс, гранд-марш кебек борынгы бию серләренә төшенгән. Бу көнне алар, барлык осталыкларын күрсәтеп, бөтен тамашачыны таң калдырды.

Проект җитәкчесе Далия Мөхәмәтҗанова сүзләренә караганда, мондый баллар Казан император университетында уздырылган. КФУда үткәрелә торган балның башкалардан аермасы: ул бернинди яңалыкларсыз, булган традицияләргә генә нигезләнә. Катнашучылар арасында, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты студентларыннан тыш, башка бүлекләрдән катнашучылар да күп иде. Гаммәви коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты студенты Раина Гәрәева үз фикерләре белән уртаклашып: «Бал узачагы турында ишеткәч, элекке чор традицияләренә, мәдәниятенә якынаясым килде. Костюмнарны туй күлмәкләре һәм карнавал өчен костюмнар сата торган салоннардан алдык. Озак әзерләндек, бераз арытты да. Ләкин мин нәтиҗәдән канәгать, куйган максатка ирештем, алырга теләгән эмоцияләрне алдым», – диде.

«Язгы бал» әкияте чынга ашты! Катнашучылар XXI гасырдан XIX гасырга әйләнеп кайттылар. Биредәге атмосфера, ягымлы карашлар, берсеннән-берсе матур костюмнар, яшьләрнең берберсенә мөнәсәбәте бәйрәмнең югары дәрәҗәдә узуы турында сөйли. Оештыручылар исә, аны университет кысаларыннан чыгарып, шәһәр күләмендә уздыру турында хыяллана. Әгәр быел катнаша алмый калгансың икән, бер дә борчылма. Бай тарихы булган уку йортында әлеге бәйрәм күркәм традициягә әйләнер һәм син дә анда катнаша алырсың!

**• Безнең тышлык**

Студент нинди булырга тиеш? Әйе, ул – акыллы, укуга мөкиббән, тырыш, актив, спортны, иҗатны якын итүче кеше! Әмма һәр студент та әлеге сыйфатларга ия булып бетә алмый. Шулай да, андый кешеләр бар! Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтының 4 курс студенты Лилия Әхмәтҗанова исемен ишетүгә, күпләрнең күз алдына бар җирдә дә өлгер, актив туташ килеп басадыр! Әйтерсен, ул бер үзе генә түгел!.

**Алинә САДЫЙКОВА**





# «Шпагатка утырырга гына өйрәнәсе калды!»





Лилияне, мөгаен, гадәти тормышка караганда, сәхнәдә ешрак очратып буладыр. Бу гаҗәп тә түгел. Әле бик яшь булуына карамастан, аның инде театраль студиясе, иҗади остаханәсе бар.

Лилия җитәкләгән «Theatron» иҗади берләшмә әле бик «кечкенә», аның барлыкка килгәненә нибары ел ярым. Команда, бик яшь булуга карамастан, үз аудиториясен булдырып, тамашачы мәхәббәтен яуларга өлгергән. Иҗади коллективның театраль юнәлештәге төрле чыгышлары күпсанлы фестиваль-конкурсларда призлы урыннар яулый, югары бәягә лаек була.

Команданың уңышында җитәкченең роле бик зур. Бу очрак та искәрмә түгел. Актив, талантлы, шат күңелле, позитив, иҗат дулкынында йөзүче Лилия барлык лидерлык сыйфатларына да ия. «Театр – ул минем тормыш. Үземне аннан башка күз алдына да китерә алмыйм. Моны минем күңелем таләп итә!» – дип елмая кыз.

Лилия иҗат дөньясына ничек килеп эләккән соң? Бераз хатирәләргә бирелеп: «Барысы да укырга кергәч, беренче курста ук башланды. Минем беренче чыгышым «Демоническая женщина» монологы булды. Аның белән мин республика күләмендә оештырылган «День первокурсника» бәйгесендә беренче урынны яуладым. Шуннан башланып китте инде», – дип искә төшерде.

Иҗади остаханәне исә Лилия 3 курста укыганда оештырып җибәрә. Активистның әлеге идеясен университетның студклубы да хуплап чыга һәм һәрьяклап аны тормышка ашыруда ярдәм итә. Шулай итеп, уртак көчләр ярдәмендә, иҗади төркемгә нигез салына.

Коллективта – 29 кеше. Шуны әйтергә кирәк: монда республикабызның башка уку йортлары студентлары һәм аспирантлары да бар икән. Репетицияләре, гадәттә, атнага 3 тапкыр була. Әмма бәйгеләр алдыннан очрашулар ешая. Хәзер аларның бар көчләре республикакүләм «Студентлар язы» фестиваленә әзерләнүгә юнәлгән. Күптән түгел Казан федераль университетында булган «Студентлар язы»ннан да читтә калмыйча, төрле институтлар исеменнән, 5 номер куйганнар. «Номерларны, гадәттә, классик әдәбиятка нигезләнеп, бүгенге көнгә якынайтып әзерлибез. Тулысынча үзебез иҗат иткән чыгышлар да бар. Мисал өчен, узган ел без «Укытучылар тангосы» исемле номер куйдык. Аның өчен монологларны үзебез уйлап чыгардык», – диде җитәкче кыз, сәхнә дуслары белән дә горурланып.

Актерлык эшчәнлеге җыр-биюдән аерылгысыз. Профессиональ дәрәҗәдә булмаса да, Лилия матур җырлый һәм бии икән. «Мәктәптә укыганда, вокал түгәрәгенә йөрү хәзер үз җимешләрен бирә», – ди ул.

Театраль осталыгының бер чагылышы буларак, ул төрле видеороликларда төшә. Күптән түгел генә уку йортыбызның «UNIVERSMOTRI.RU» каналы аңа бер проект тәкъдим иткән. Бик тиздән Лилияне университетыбыз телеканалында да күрү бәхетенә ирешәчәкбез.

Лилия бөтен вакытын әлеге иҗади остаханәгә генә багышлый икән, дип уйласагыз, ялгышасыз. Ул әле чит телләр белән дә кызыксына. Инглиз теле буенча белемнәрен камилләштерергә, француз телен тирәнтен өйрәнергә тели. Бу елның җәендә чит илгә, Америкага, барырга хыяллана. «Киләчәктә күбрәк сәяхәт итәсем, дөнья гизәсем, яңа җирләр күрәсем килә», – ди ул.

Кызның тыгыз графигында спорт өчен дә вакыт бар. Аны фитнес залларында очратырга мөмкин.

«Боларның барысына ничек берьюлы өлгереп була соң?» – дигән сорау белән мөрәҗәгать иттем. «Вакыт бик тиз үтеп китә. Шулай да, ничектер өлгерәм инде. Әнием, кайчакта, яртышар ел өйгә кайтмаган өчен ачулана», – дип елмайды Лилия. Барысын да булдырган кыздан: «Эшли белмәгән әйберең бармы соң?» – дип сорагач: «Шпагатка утырырга өйрәнәсем килә», – диде ул.

Лилия иҗатташ дусларының да киләчәктә әлеге осталыкларын үстерүләрен, театр казанында кайнауларын, тормышларын иҗат белән бәйләүләрен тели. «Бергә без барысын да булдырачакбыз! Үземә килгәндә, мин киләчәгемне иҗатсыз күз алдына китерә алмыйм! Дөресен генә әйткәндә, 10 елдан ни көткәнен әйтеп булый. Ләкин үземнең һәм якыннарымның бик бәхетле булуларын телим!»

Лилия Әхмәтҗанованы истә калдыр, дустым! Бик тиздән без аны зур экраннарда да күрербез әле!

**• Безгә язалар**

*Исәнмесез, хөрмәтле «Дарелфөнүн» газетасы редакциясе хезмәткәрләре. Мин Казан шәһәре Идел буе районының 42нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, КФУның Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең 1 курс магистранты Регина Раянова булам. Безнең мәктәптә һәр көн саен диярлек күңелле чаралар уза. Шуның берсе турында сезгә язып җибәрергә булдым. Сезнең газетаны студентлар гына түгел, мәктәп укучылары да кызыксынып укый. Алга таба да уңышлар телибез.*

# Рәхмәт сиңа, Әлифбам!

Кабатланмас балачак иленең иң зур бәйрәмнәреннән берсе – Әлифба бәйрәме. Җир йөзендә кем генә булмасын, кайда гына эшләмәсен, ул зур дулкынлану белән үзенең нәни кулларына тәүге тапкыр Әлифба алганын искә төшерә. Чөнки һәркемнең дә белем дөньясына беренче адымы Әлифбадан башлана. Димәк, Әлифба китабы озын гомерле, тирән мәгънәле, бәһасез байлык ул.




Әйе, бүгенгедәй күз алдымда, әле кайчан гына туган авылым Түбән Аташның кечкенә мәктәбендә Әлифба бәйрәмебезне үткәргән идек. Баксаң, инде бу вакыйгадан соң 16 яз, җәй, көз һәм кыш үткән. Күпме утлар-сулар кичелгән, алда биек таулар булып торган максатларга ирешелгән. Сабакташларымның күбесе инде тормышта үз юлын табып, гаилә корып, балалар тәрбияли.

Безне укырга, язарга, сөйләргә, саннар белән эш итәргә өйрәткән, гомумән, зур тормышка әзерләгән беренче укытучыбыз Нәфия апа күңел түрендә изге фәрештә булып саклана.

Язмышка язылганны алдан күреп булмый шул... Кичәге Нәфия апабыз урынында бүген мин үзем басып торам. Тирә-ягымда беренче сыйныф укучылары гөр килеп шигырь сөйләргә әзерләнә. Ә залга әлеге сабыйларның әти-әниләре, әби-бабайлары җыелган.

Әлбәттә, бүгенге бәйрәмгә килеп җиткәнче урау юллар аша узарга туры килде. Без укучылар белән хәрефләр танырга, хәрефләрдән иҗекләр, иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән җөмләләр төзергә өйрәндек. Кыскасы, хәзер безнең алда кечкенә балалар түгел, ә укый, яза, җырлый, бии, шигырь сөйли белгән укучылар басып тора. Монда инде укытучы, укучы, әти-әниләрнең – барыбызның да тырышлыгы бар. Шуның өчен Әлифба бәйрәме – һәммәбез өчен дә зур тантана. Бәйрәмебез котлы булсын!

Сүзем күптән түгел генә шәһәребезнең 42нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә шаулап-гөрләп үткән «Рәхмәт сиңа, Әлифбам!» дип аталган әдәби-музыкаль кичә турында.

Бәйрәмне татар теле һәм әдәбияты укытучылары Лира Габдрахман кызы Вәлиева, Алисә Дамир кызы Хәкимова һәм Регина Рәфис кызы Раянова әзерләде. Зал, искиткеч матур итеп, шарлар, плакатлар белән бизәлгән иде, беренче сыйныф укучылары, тәүге тапкыр сәхнәгә чыгуларына карамастан, матур һәм сәнгатьле итеп шигырьләр сөйләде, җырладылар. Диана Дәүләтшина туган илгә мәхәббәт хисләрен чагылдыра торган халык җыры «Шома бас» җыры белән өлкәннәрне куандырды. Биюче кызлар Мәликә, Ильвина һәм Камилә дә сынатмады.

Харис абый Нигъмәтҗанов җитәкчелегендә «Курайчы»лар төркеме җыры булды. Өченче сыйныф укучылары үзләре курай, гармунда уйнап, моңлы җырлар башкарды. Гармунчыларның берсе вьетнам кызы булуы тагын да күңелне күтәрде.

Кичәбез азагында Г.Тукайның татар халкының милли гимнына әйләнгән «Туган тел» җырын балалар һәм укытучылар аягүрә басып башкарды.

Рус мәктәбе булуына карамастан, туган телебезне хөрмәт иткән, борынгыдан килгән рухи байлыкны, гореф-гадәтләрне, телне сакларга тырышкан укучылар укый бирәдә. Залдагы әти-әниләр дә шушы хакта уйланып шатланганнардыр.

Әйе, теле барның – иле бар. Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр! Газиз туган телебез – татар теле киләчәктә дә балкып чәчәк атар дигән теләктә каласы килә.

DARELFØNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.